Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАРЫ I-3**

Балык Бистәсе штп 2020 елның 23 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә һәм аны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2010 елның 15 октябрендәге I-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә уздырырга.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итү буенча 2020 елның 28 сентябреннән 2020 елның 17 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе ш.т.б., Ленин ур., 48 й. 23 каб. Кабул итү вакыты: 8:00 дән 12:00 гә кадәр һәм 13:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр (ял һәм бәйрәм көннәреннән кала). Элемтә өчен телефон: 8(84361) 22-128 (Шелкова Светлана Александровна), факс: 23-012. E-mail: Svetlana.Shelkova@tatar.ru.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары Башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфасын биләүгә кандидатуралар билгеләү турында» 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы Указларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе (алга таба - конкурс комиссиясе) составын «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфасын биләүгә кандидатуралар билгеләү турында» 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы,

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары Башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлегенә үзгәреш кертү турында» 2019 елның 19 июлендәге ПУ-419 номерлы Указларын исәпкә алып расларга.

3. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурсны 2020 елның 26 октябренә кадәр үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына кандидатлар турында мәгълүмат бирергә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурста катнашу өчен конкурс уздыру һәм документлар кабул итү турындагы хәбәрне «Авыл офыклары» район газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru » һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2020 елның 23 сентябрендәге I-3 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе составы**

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Эш урыны, вазыйфасы | Кем тарафыннан билгеләнгән | Комиссия составындагы статус |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Җамалиев Рөстәм Рәсим улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы | Комиссия рәисе |
| 2. | Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры | Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан | Комиссия рәисе урынбасары (килештерү буенча) |
| 3. | Шелкова Светлана Александровна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы | Комиссия секретаре |
| 4. | Гаффаров Раил Равил улы | Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе | Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан | Комиссия әгъзасы (килештерү буенча) |
| 5. | Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе башлыгы | Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан | Комиссия әгъзасы (килештерү буенча) |
| 6. | Сәйфуллина Лилия Җәүдәт кызы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы | Комиссия әгъзасы |